# Ислам нуры

«Диндә көчләү юк, ләкин өндәү һәм өйрәту бар»
(Коръән Кәрим. 2-256)

12+

№ 24 (700) 24 декабрь 2019 ел (1441, Рабигуль-ахир) Дини-иҗтимагый газета 1995 елдан чыга


## Бәхетне каян эзләргә?



Мал — әгәр дә Аллаһы Тәгалә хәзрәте боерган рәвешчә сарыф ителмәсә, бәндәне адаштыруга сәбәп булыр, шуның өчен малның үзен сөймәгез вә Аллаһы Тәгалә хәзрәте риза булмаган урыннарга сарыф итмәгез, сак булыгыз! Бәндәнең Аллаһы Тәгалә хәзрәтенә тоташтырачак дине, әдәбе вә гүзәл холкы булмаса — дөнья тулы малы булса да бер файдасы булмас. Шуның өчен, малыгыз никадәр күп булса-булсын, дин тәрбиясе алыгыз, гыйлемле, әдәпле, гүзәл холыклы булыгыз! Дөньягыз тар булса, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтеннән өмет өзмәгез, иркен булганда азгынлык вә җенси дәрт колы булмагыз, байлык — бер айлык икәнлеген вә күп бай фамилияләр азгынлыклары сәбәпле иң фәкыйрь булып калуларын фикерләп, күңелләрегезне, үз-үзегезне тәрбия итеп торыгыз! Акчаның үзен сөю — иң каты фәкыйрьлектер. Адәм баласы акчасыз фәкыйрьлеккә сабыр иткән хәлдә, акча сөю фәкыйрьлегенә сабыр итә алмас. Әгәр дә адәм баласы, Алла сакласын, акча сөю фәкыйрьлегенә дучар булса, бөтен тереклеге хәсрәтле булыр, адәмчелеге вафат булыр, кара икмәккә туймыйча, башын ташка куеп яткан фәкыйрьләр күрмәгән мәшәкатьләрне акча сөюдә булган бай фәкыйрьләр күрерләр. Сез бу хәлне һәрвакыт алдыгызда тотыгыз, акчасызлык фәкыйрьлегеннән артык акча сөю фәкыйрьлегеннән куркыгыз, сакланыгыз! Гадәти рәвештә генә дөнья кичереп риза вә Аллаһы Тәгаләнең өлешләвенә буйсынып, үзеннән түбәннәрнең хәлен күреп шөкер итүдә булган зат биек сарайларда утырып вә һәртөрле зиннәтләргә туеп та, үзеннән югарыларны күреп вә алар кебек булмавы өчен кайгыруда булган кешедән кат-кат бәхетледер. Шуның өчен сез дә бәхетне байлыктан, яки ат, арба вә олы сарайлардан эзләмичә, бәлки күңелегезнең канәгатьле вә җаныгызның тыныч булуыннан эзләгез!

**(Риза ФӘХРЕДДИН, “Әхлак гыйлеме”ннән.**
*Фото интернеттан алынды.*)

## ТР МДН хәбәр итә



Рабигуль-ахир аеның 22 нче көнендә Казанда Татар Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүнең 100 еллыгы Елы ачылуны тантаналы рәвештә билгеләп үттеләр. Кичәнең мәртәбәле кунаклары арасында Татарстан мөселманнары башлыгы, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин да булды. Чара барышында рәсми һәм иҗади чыгышлардан тыш, яңа дәүләт бүләге – «Татар Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале тапшырылды. Бу медальне республика Президенты Рөстәм Нургали улы кулыннан алуга Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин да лаек булды. ТР Президентының 2019 елның 19 декабрендә имзаланган «Бүләкләү турындагы...» Указында билгеләп үтелгәнчә, ТР мөселманнары Диния нәзарәте башлыгы «Татарстан Республикасының социаль-икътисадый куәтен, милләтара һәм конфессияара дуслыкны һәм тынычлыкны ныгытуга, милли-рухи мирасны саклау һәм арттыруга зур өлеш керткәне, һөнәри һәм җәмәгать эшчәнлегендәге югары казанышлары өчен» бүләкләнә.

***



Рабигуль-ахир аеның 22 нче көнендә, Казанның Галиев мәчетендә «Яшь вәгазьче» дип исемләнгән республика дини бәйгесенең йомгаклау өлеше уздырылды. Бәйге нәтиҗәләре буенча абсолют җиңүче исемен “Мөхәммәдия” мәдрәсәсенең II курс шәкерте – 24 яшьлек Саба егете Альмир Исмәгыйлев яулады. Лениногорск оешмаларының берсендә токарь булып эшләүче 25 яшьлек Илназ Шәрипов II урынга лаек дип табылды. III урында – тумышы белән Буа егете, РИИ каршындагы Коръән-хафизлар әзерләү үзәгенең I курс студенты 21 яшьлек Идрис Сөләйманов. Җиңүчеләргә акчалата бүләкләр, барлык катнашучыларга сертификатлар һәм дини әдәбият тапшырылды. Моннан тыш, иң яхшы вәгазьләр «Шура» альманахында басылып чыгачак.

## Чаллы яңалыклары




18 декабрь көнне Чаллы шәһәрендә “Alif” дип аталган хәләл кунакханә ачылды. Әлеге чарага Чаллы мәчетләре имамнары чакырылган иде. Мәҗлесне кунакханә проекты җитәкчесе Рөстәм Гатин алып барды. Үзенең чыгышында ул мондый кунакханәләрнең



Рәсәй җирлегендә, Чечня республикасыннан кала, башка булмавын ассызыклап үтте, соңрак кунакханә бүлмәләре белән танышу булды. Мәҗлес чәй өстәле артында дәвам итте һәм бина эчендә булдырылган гыйбадәт бүлмәсендә өйлә намазы белән тәмамланды.

***

“ТР МДН Хаҗ” агентлыгының Чаллы шәһәрендәге вәкиллеге аша хаҗ сәфәрен кылучылар өчен атнага бер тапкыр хаҗ дәресләре башланып китте.

***



17 декабрь көнне, “Асылташ” балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приюты һәм “Ихсан” фонды бергәләп игелекле акция уздырды: безнең якларда кышлаучы кошлар өчен җимлекләр ясадылар. Соңрак аларны тагын шулай бергәләп шәһәр паркына урнаштырачаклар. Мондый чаралар балаларның күңеленә мәрхәмәт, тирә-юньгә шәфкатьле мөнәсәбәт орлыклары салырга ярдәм итә. Ә бу исә тәрбиягә авыр бирелүче үсмерләр өчен аеруча мөһим.

Теләгән һәркем “Ихсан” фонды оештырган проектларда катнаша ала. 879179236072, 879179316571 телефоннары аша элемтәгә керергә була.

# Әюп пәйгамбәр

Кадерле дин кардәшләрем!

Без бүген Әюп галәйһиссәлләмнең тормыш юлы белән танышырбыз.

Тарихчылар Әюпне яһүд халкыннан дисә дә, аның шәҗәрәсе Ибраһим галәйһиссәлләмгә тоташуын күрәбез. Аллаһы Тәгалә бу турыда әйтә: ..."Ә аның нәселеннән Даудны, Сөләйманны, Әюпне, Йосыфны Мусаны, Харунны.."

Әюп галәйһиссәлләмнең тарихы, гадәттә, авырлыкларга бирешмәү, авырлыклар килгәндә нык булу һәм дә Аллаһы Тәгаләнең тәкъдиреннән канәгать булу үрнәге итеп күрсәтелә.

Бүгенге хөтбәдән барыннан да бигрәк авыр ситуацияләргә эләккән яки бик нык авыручылар файда алырлар. Без барыбыз да беләбез, бу дөньяда сынаулар килмәгән кеше юк. Кайберәүләр бу сынауларга түзә алмыйлар һәм Аллаһы Тәгаләгә шушы сынауны җибәргәне өчен ачулана башлыйлар, тәкъдиреннән канәгатьсезлек күрсәтәләр. Алар шушы авырлыклар килгәнгә Аллаһы Тәгаләне гаепли башлыйлар, Аның кушканнарын үтәмиләр һәм хәрәм кылалар. Алар бу дөньяның сынау икәнен онытталар. Бу дөньяның ләззәт өчен түгел, ә безнең өчен имтихан, сынау, безне тикшереп карау өчен икәнен оныталар. Бу дөньяны Аллаһы Тәгалә "әд-дунья" дип атый. Гарәп теленнән тәрҗемә иткәндә, түбән, әһәмиятсез дигәнне аңлата. Чөнки бу дөньяда кеше ял итми, ул гел имтихан тота. Хаклыкта, ял һәм шатлыклар бары җәннәттә генә булачак. Нинди генә шатлык килмәсен бу дөньяда, ул кайгы, хәсрәт белән алышынып тора. Ә җәннәттә беркайчан да бетми торган шатлыклар, яшьлек булачак. Чирләр, картлык булмаячак.

Әйдәгез әле, Әюп (г.с.) белән якынрак танышыйк. Тарихчылар һәм хәдис белгечләре әйтүенчә, Әюп (г.с.) бик бай, дәрәҗәле кеше саналган. Аның бик зур кишәрлек җирләре һәм бик күп балалары булган. Һәм ул бик бәхетле кеше булган. Җаны ни теләсә, шул бар.

Бераз вакыттан ул боларның барысын да югалта. Аллаһы Тәгалә бар биргән нигъмәтләрен алып, сыный аны. Барлык балалары һәлак була, ә үзе бик каты авырый башлый. Бөтен тәнен зур-зур сасы исле сыткычлар басып ала, тәненнән кан, үлек агып тора башлый. Тәне шулкадәр чирканыч була, янына килмәслек җирәнгечкә әйләнә. Ул йөри алмаслык халәткә җитә, урын өстенә кала. Бары һәрвакыт Аллаһны зекер итүче теле белән йөрәген генә бу чир биләп ала алмый.

Җәмәгать! Әюпнең сынавы мал-мөлкәтен югалту гына булса, бу бик җиңел сынау булыр иде. Мал ничек килсә, шулай китә дә бит ул. Исегезгә төшерегез әле, күпме байлар, хөкемдарлар бик тиз арада бар булган байлыкларын, дәрәҗәләрен югалттылар. Һәм, киресенчә, күпме ярлы кешеләр күпмедер вакыттан баеп киттеләр. Тырышсаң, һәм сабыр итсәң, мал-мөлкәтне генә кайтарып була ул.

Әмма Әюпкә кайгы өч яклап килә:

1. Ул булган бар мал-мөлкәтен югалта.

2. Аның барлык балалары һәлак була.

3. Ул урыныннан тора алмаслык авыр чир белән авырый башлый.

Ә бит ул бу чир белән бер-ике ай гына чирләми, унсигез ел буе иза чигә. Авыруына карамастан, унсигез ел буе ул бер намазын калдырмый, Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кыла. Бу сынаулар килгәнгә бер тапкыр да канәгатьсезлек күрсәтми. "Ник соң Аллаһы Тәгалә миңа мондый сынаулар җибәрә?"- дигән зарланулар аның уена да керми.Кайберәүләр әйтүенчә, Әюп:

"Йә Аллаһ! Бу чир минем телемә тимәсен, миңа телем белән Сине зекер кылырга комачау итмәсен", - ди. СөбханәАллаһ! Шушы халәтендә дә ул Аллаһы Тәгаләне онытмый. Ничек кенә авыр чирләвенә карамастан, аның йөрәге сәламәт, таза, чиста булып кала. Ә күпме сәламәт, таза кешеләрнең йөрәкләре тулы чир бүген! Күпме кешеләрнең куллары, аяклары исән булуга карамастан, Аллаһы Тәгаләгә сәҗдә кылмыйлар. Аллаһка гыйбадәт кылуны кирәксенмиләр.

Тарихчы Судди җиткерә: "Әюп шулкадәр нык чирли, ул тире белән сөяккә генә кала. Моны күреп бик кайгырган хатыны аңа: "Йә Әюп! Бәлки, син Аллаһтан бу чиреңнән арындыруын сорарсың?" - ди. Әюп аннан: "Мин ничә ел сәламәт булып яшәдем?" - дип сорый. Хатыны: "Җитмеш ел", - дип җавап бирә. Шуннан Әюп: "Мин Аллаһтан бу турыда сорарга оялам. Чөнки Ул миңа моңынчы җитмеш ел буе сәламәтлек биргән иде", - дип җавап кайтара. Карагыз әле, ничек ярата ул Аллаһы Тәгаләне! Ничек хөрмәт итә ул Аны һәм ояла ул Аннан! Әюп, Аллаһы Тәгалә нәрсә бирсә, шуннан канәгать. Тәкъдиреннән канәгатьсезлекнең әсәре дә юк!

Бераз вакыттан кешеләр, Әюпнең чире йогар дип куркып, аларны шәһәрдән куып чыгаралар. Хатыныннан башка бөтен кеше диярлек ташлый аны. Ә хатыны бертуктаусыз ирен карый. Аны ашата, эчертә. Канын, сасы исле үлекләрен гел чистартып тора. Әюп янына шулай ук ике абыйсы да килгәләп йөриләр. Күпмедер вакыттан соң аларның бар булган мөлкәтләре бетә. Һәм Әюпнең хатыны, әзрәк ризык юнәтү өчен, кешеләргә ялланып эшли башлый. Әмма бераздан кешеләр, иренең чире йогар дип куркып, аны эшкә алудан туктыйлар. Шулвакыт Әюпнең хатыны, әзрәк булса да ризык булмасмы дип, бик матур, озын чәчен кисә, аны сатып, бераз ризык юнәтә.

Җәмәгать! Бүгенге көндә кайбер хатыннар ирләре эшсез калгач, яисә сәламәтлекләре белән проблемалар башлангач, ирләрен калдыралар, мине ирем тәэмин итә алмый, үзенең бурычын үтәми дип, талак сорап, казыйларга баралар. Лә иләһә иллә Аллах... СөбханәАллах! Ә безнең әбиләребез нинди булган соң? Сәхәбәләр, табигыйннәрнең хатыннары нинди булган? Ирләре өйгә кайткач, алар: "Син бүген Аллаһы Тәгаләнең һәм Пәйгамбәрнең нинди сүзләрен өйрәндең? Алып кайткан малыңны хәләл юл белән таптыңмы, әллә хәрәм юл беләнме? Миңа Аллаһы Тәгаләнең ут җәзасын алуга караганда, ач тору күпкә җиңелрәк", - дип ирләрен каршылаганнар. Ирләренең ихтыяҗы булмаса, аннан ризалык алып, төне буе намаз укыганнар. Йә Аллаһ, безнең хатыннарыбыз, кызларыбыз, апа-сеңелләребез элгәре булган тугры хатыннар кебек булсыннар иде.

Әюпне тагын ике абыйсы вакыт-вакыт килеп караштыра торган булганнар, дип әйткән идем. Менә беркөнне шуларның берсе икенчесенә: "Күрәсең, Әюп бик зур гөнаһ кылгандыр. Чөнки Аллаһы Тәгалә аның хәлен җиңеләйтми, рәхимлек күрсәтми аңа, аннан бу авыр йөкне алып атмый. Әнә бит Ул аны ничек авыр җәзалый", - ди. Бу фикерне тыңлап торган абыйсы түзми, Әюпкә ике туган арасында булган бу сөйләшүне түкми-чәчми сөйләп бирә. Әюп: "Мин бервакыт урам аша чыкканда ике кешенең берберсе белән талашуын ишетеп алдым. Аларның берсе икенчесенә ант итте. Өйгә кайткач, мин аның антын гафу итүне сорадым. Чөнки мин Аллаһы Тәгаләнең исемен теләсә ничек искә алуларын теләмим. Шуннан башка бернинди андый нәрсә кылганымны хәтерләмим", - ди. Ә хәзер үзебезгә игътибар итик әле. Без үзебезнең дөрес икәнебезне дәлилләү өчен Аллаһ белән ничә тапкыр ант итәбез? Әйткән сүзләребезгә әһәмият тә бирмибез. Уйланыгыз! Син бит Бөек Аллаһ белән ант итәсең. Әюп кемнеңдер Аллаһ белән ант итүен күтәрә алмаган һәм аларның анты өчен Аллаһтан гафу үтенгән. Шулхәтле хөрмәт һәм ярату аның йөрәгендә Аллаһка карата.

Шуннан нәрсә булган соң? Без беләбез, Аллаһы Тәгалә һәрвакыт үзенең пәйгамбәрләренә ярдәм итә. Аллаһы Тәгалә әйтә: "Хаклыкта, Без пәйгамбәрләребезгә һәм Коръән белән гамәл кылучы мөэмин бәндәләребезгә дөньяда һәм ахирәттә шаһитләр җыелган көндә ярдәм бирәчәкбез".

Ничек кенә авыр булмасын, Аллаһы Тәгалә сабырлык өчен Үзенең бәндәләрен бүләкли.

Әюпнең авыруы бик каты була, алдан әйткәнебезчә, ул көч-хәл белән йөри. Күп вакыт ул хатынының ярдәменә мохтаҗлык кичергән. Гадәттә, хаҗәте җитсә, ул хәләл җефетен чакырып алган һәм хатыны аны хаҗәтен үти торган җиргә алып барган.

Беркөнне хатыны Әюпне гадәттәгечә хаҗәтен үтәргә калдыргач, ул Аллаһка мөрәҗәгать итә: "Йә Раббым, мине сырхау вә катылык тотты, вә Син рәхмәт итүчеләрнең иң Рәхимлесе". ("Әнбия", 83).

Игътибар итегез, җәмәгать! Ул Аллаһтан: "Йә Аллаһ! Миңа шифа бир", - дип сорамый. Ул: "Йә Раббым, мине сырхау вә катылык тотты, вә Син рәхмәт итүчеләрнең иң Рәхимлесе", - ди. Ул үзенең нинди халәттә икәнен генә хәбәр итә. Бу сүзләрне ул бары унсигез ел буе сабыр иткәннән соң гына әйтә. Шуннан могҗиза була. Аллаһы Тәгалә аның догасына җавап бирә: "Аның догасын кабул иттек".

Аллаһы Тәгалә аның догасына ничек итеп җавап биргән соң? Ул Аллаһы Тәгаләгә мөрәҗәгать иткәч, Аллаһы Тәгалә: "Аягың белән җиргә тип, дип әйтелде, типкәннән соң салкын чишмә, юынырга кайнар чишмә чыкты". ("Сад", 42)

Аягы белән җиргә тибүгә, бу урыннан чишмә бәреп чыга. Чишмә суын эчкәч, Әюп аның суы белән юына. Юыну белән аның тәне чирдән арына. Ул бу авыр чиреннән терелеп кенә калмый, ә матурланып, яшәреп, үзгәреп китә. Аллаһы Тәгалә аңа көчле, куәтле тән бирә. Шуннан хатыны янына чыга. Хатыны аны танымый. Әюпне күреп, ул аннан: "Син анда Аллаһы Тәгалә чир белән сынаган пәйгамбәрне - минем иремне күрмәдеңме?" - дип сорый. Әюп: "Мин бит инде ул", - дип җавап бирә. Хатыны үз күзләренә ышанмыйча: "Син Әюпмени?" - дип сорагач, ул: "Әйе, мин - Әюп. Аллаһ мине савыктырды", - ди.

Моның белән Аллаһның нигъмәте чикләнми. Әюпнең иген һәм арыш үстерә торган ике кишәрлек җиренә Аллаһы Тәгалә болытларга әмер биреп, бу басуларга тулганчы алтын һәм көмештән торган яңгыр яудыра. Аннан вафат булган балалары урынына тагын шуның кадәр бала бирә. Аллаһы Тәгалә бу турыда: "Без аның догасын кабул иттек, вә аңарда булган сырхау һәм бәлане җибәрдек, вә аңар өй әһелләрен кайтарып бирдек, вә балаларын, малларын ике өлеш арттырып бирдек. Үз хозурыбыздан рәхмәт йөзеннән, вә Аллаһ колларына гыйбрәт булсын өчен". ("Әнбия", 83-84)).

Аллаһы Тәгалә Әюп турындагы тарихны тәмамлап: "Хакыйкатьтә Без Әюпне бәла-казага, вә сырхауга сабыр итүче таптык. Ул Әюп ни хуш бәндәдер, вә ул Аллаһка нык кайтучыдыр", - ди.

Бу танылган вакыйга Аллаһы Тәгалә җибәргән сынауларга нык тору, сабыр булу үрнәге. Йә Аллаһның колы! Сиңа килгән сынаулар никадәр авыр булмасын, Әюпкә килгән сынаулар тагын да авыррак булган.

Үзебезнең арадан да бу вакыйгаларга туры килә торган мисаллар бар. Мәсәлән, татар галиме, хәзрәт Габделгали бине Гобәйдулла турында мисал китерәсем килә. Ул Ризаэддин Фәхреддиннең остазы була. Ул бөтен гомерен шәригать гыйлемен алуга һәм аны таратуга багышлый. Күп еллар гыйлем алганнан соң, 1841 нче елны Бөгелмә районына кайта. Анда әтисенең мәдрәсәсендә укытуны дәвам итә. Бу мәдрәсәне саклап калуда зур роль уйный. Аннан гомеренең соңгы көннәренә кадәр шунда укыта. 60 ел буе йөзләрчә имам, укытучы, галим чыгара ул, гарәп телендә бик күп китаплар яза. Һәм 1901 нче елда вафат була. Аллаһы Тәгалә Габделгали хәзрәткә дә бик күп сынаулар җибәрә. Мәсәлән, үләренә биш ел кала ул сукырая, әмма җәмәгать намазларын калдырмый. Икенче бер сынау аның гаиләсе белән бәйле. Беркөнне аның йортына ут каба һәм бу янгында аның өч баласы: Мәсагад, Мөфәззал, Сафия һәлак була. Бөтен авыл белән кайгыралар. Әмма моңа карамастан, ул җәмәгать намазына бара һәм җыелган халыкка әйләнеп утыра. Аннан дога кылганнан соң, «Аллаһы Тәгаләнең хөкеменә риза булмаудан түгел, бәлки янып көл булган угыл вә кызларның үзләрен кызганамын!» - ди. Һәм шуннан балалары хакында гомере буе бер сүз сөйләгәне ишетелми. 1899 нчы елда аның өе тулысынча яна, әмма аның йөзендә кайгы юк һәм Аллаһ Тәгалә тәкъдиренә ризасызлык күренми.

Ризаэддин Фәхреддин: "Бу галимнең үзенчәлеге шунда - ул үзенең улы Мәсгудне галим итеп тәрбияләп үстерә", - ди. Ул вакытларда Галимҗан Баруди мөфти була. Галимҗан Баруди үлгәннән соң, Ризаэддин Фәхреддин, Мәсгуд мөфти булачак дип уйлый. Аның мөфти урынына калачагына ул хәтта шикләнми. Әмма Аллаһы Тәгалә Габделгали улы Мәсгудне Үз хозурына чакырып ала, һәм бу авыр сынаудан азат итә.

Без дә үзебездән алда килгән буыннардан үрнәк алып, ныклы рухлы булсак иде.

**Әбүбәкер хәзрәт ӘБДИЕВ,**
**Чаллының "Тәүбә" мәчете имам-хатыйбы.**

# Кыямәт көненең галәмәтләре

*(Дәвамы. Башы газетаның алдагы саннарында)*

Әле булмаган (киләчәктә булырга тиешле) кече галәмәтләр.

1. Хайваннарның кеше белән сөйләшүе, шулай ук җансыз әйберләрнең сөйләшүе.

Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтте: “Хайваннар һәм җансыз әйберләр кешеләр белән сөйләшә башламыйча кыямәт көне килеп җитмәс”.

Әгәр Мөхәммәд (с.г.в.) заманында кешеләргә радио, телевидение яки компьютер, ягъни кеше тавышын яңгырата торган җансыз әйберләрнең “сөйләшүе” турында әйткән булсалар, бу алар өчен чынга ашмаслык бер хәл, фантастика буларак тоелыр иде, әмма хәзерге заманда бу нәрсәләр инде бар һәм алар гадәти бер нәрсә буларак кабул ителә. Аллаһы Тәгалә җир һәм күкләрнең бөек Яратучысы һәм барлык нәрсәләр Аның ихтыярына һәм кодрәтенә буйсына. Әлбәттә, әгәр Аллаһ теләсә, хайваннар да, җансыз әйберләр дә сөйләшә башларга мөмкин.

2. Айның бик зураеп китүе (ике тапкырга).

Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтте: “Кыямәт көне якынаюның бер дәлиле - айның зураюы”. Галимнәр аңлатулары буенча, айның зурлыгы ике тапкырга артачак (бу, бәлки, аның җиргә якынаюына бәйледер).

3. Гыйрак җирлегендәге Ефрат (Форат) елгасы астыннан алтын тауның чыгуы.

Имам Бохари һәм Мөслим китапларында Әбү Хөрайра исемле сәхабәдән шундый хәдис китерелә: “Ефрат елгасыннан алтын тау чыкмыйча, кыямәт көне булмас. Кешеләр шул алтын өчен сугышып, бер-берсен үтерерләр (100 кешедән берсе генә исән калыр) һәм ул кешеләрнең һәрберсе дә үзенең генә исән калуын өмет итәр”. Имамнар Бохари һәм Мөслим шул алтынны беркем дә ала алмас, дип риваять кылган.

4. Җир астындагы кыйммәтле ташларның (алтын, алмазларның һ.б.) җир өстенә чыгуы.

Бу Аллаһы Тәгаләнең әмере буенча эшләнә. Ул вакытта кешеләр күңелендә алтынга карата нәфрәт туар, аның кадере бетәр, чөнки һәркем алтынның кешене бозучы, аздыручы нәрсә булуын аңлаячак.

Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтте: “Җир үзенең байлыгын эченнән чыгарыр һәм чыккан вакытта ул баганаларны хәтерләтер (ягъни күп булыр).

**(“Ислам дине нигезләре”ннән. Дәвамы бар)**

## ӘДӘБИ СҮЗ

*Габдулла Тукай*

# Таян Аллага

*И бәһале, и кадерле, и гөнаһсыз яшь бала!*
*Рәхмәте бик киң аның,*
*һәрдәм таян син Аллага!*
*Йа Раббым, күрсәт, диген,*
*ошбу җиһанда якты юл;*
*Ул - рәхимле; әткәң-әнкәңнән дә күп*
*шәфкатьле ул!*
*Саф әле күңлең синең, һичбер бозык*
*уй кермәгән,*
*Пакъ телең дә - һич яраусыз сүзләр*
*әйтеп күрмәгән.*
*Пакъ җаның һәм пакъ тәнең –*
*барлык вөҗүдең пакъ синең:*
*Син фәрештә валчыгысың, йөзләрең ап-ак синең!*
*Кыйл дога, ихлас белән тезлән дә кыйбла каршына.*
*Бел аны: керсез күңелдән тугъры юл бар гаршенә!*
*И бәһале, и кадерле, и гөнаһсыз яшь бала!*
*Рәхмәте бик киң аның, һәрдәм таян син Аллага!*

# Һәрчак истә тот!

Кайсыберәүләр, әгәр Аллаһ ярдәм итсә яки бәла-казадан коткарса, мотлак корбан чалачакмын яки хәер бирәчәкмен, дип нәзер әйтә. Мондый нәзерләрнең нинди әһәмиятле икәнен беләсезме? Сәламәтлеге яхшы, акчасы мул, эшләре алга барган кеше Аллаһ хакында онытып җибәрә. Уңышка ирешкәннәр гадәттә үз көченә генә ышана башлый. Ә бит чак кына берәр нәрсә була калса, шунда ук Аллаһка мөрәҗәгать итәргә һәм Аңа якынаю юлларын эзләргә керешәбез. Мондый чакларда гыйлемле кешеләр догаларының кабул булуын изге эшләр башкарып тизләтергә тырышса, гыйлемсезләр исә үзләрен Аллаһка якынайта алырдай арадашчылар эзләп чаба башлый. Кайсыберәүләр, әгәр Аллаһ ярдәм итсә яки бәла-казадан коткарса, мотлак корбан чалачакмын яки хәер бирәчәкмен, дип нәзер дә әйтә. Мондый нәзерләргә күкләрдә нинди әһәмият бирелгәне хакында белсәләр иде.

Аллаһ Тәгалә бу хакта Коръәндә шулай ди: ”Алар (монафикълар) арасында, “Әгәр Ул безгә Үзенең юмартлыгыннан (байлык) бирсә, без, әлбәттә, сәдака бирер идек һәм салихлардан булыр идек”, дип, Аллаһ белән сүз куешучылар бар. Ул аларга Үз юмартлыгыннан өләшкәч, алар саранлана башлады һәм, (Аллаһка буйсынудан) читкә тайпылып, йөз чөерде. Аллаһка биргән вәгъдәләрен бозган өчен һәм алдашканнары өчен, Аның белән очраша торган Көнгә кадәр Ул аларның күңеленә нифак (икейөзлелек) салды” (”Тәүбә” сүрәсе, 9:75–77). Әйе, биргән вәгъдәне бозган өчен теге дөньяда Аллаһ “баштан сыйпамас”. Аллаһның рәхмәтеннән мәхрүм калу һәм монафикълык – ул чын җәза. Чөнки монафикълар: “Аллаһка ышанабыз”, – ди. Ниндидер изге эшләр башкару да алар өчен ят нәрсә түгел. Әмма алар, үзләрен диннең фарызлары белән артык мәшәкатьләми генә, үзләренә ничек уңайлы, шулай гына ышануны хуп күрә. Алар өчен иң мөһиме: эшләре уңышлы барсын, тормышлары – җитеш, якыннары сау-сәләмәт һәм бәхетле булсын. Ә хак мөселманнар җитеш һәм рәхәт тормышта яшәргә теләмимени? Әлбәттә, тели, һәм моны алар тик Аллаһтан гына сорый. Ләкин әгәр фани дөнья байлыгы белән үлемнән соң котылу арасында сайларга туры килсә, алар һич икеләнүсез Ахирәткә өстенлек бирәчәк. Аллаһ Тәгаләнең ризалыгы да алар өчен кешеләрнең ризалыгыннан мөһимрәк. Икейөзле бәндәләр исә мондый күркәм сыйфатларга ия була алмый.

Үзләренең тәкәбберлеге аркасында кирәк чакта гына Аллаһны искә алган кешеләр дә очрый. Әлбәттә, бер көн эчендә генә тәкәббер булып китмәгән алар. Хәләл булмаган юллар белән мал җыю һәм билгән вазифалары белән гаделсез рәвештә эш итү үзгәртә андыйларны. Аллаһны онытканы өчен Аллаһ аларның кем булуын һәм бу җиргә ни өчен җибәрелгәнен онытырга мәҗбүр итә. Шуңа да алар менә нәрсә ди: “Башкалар ял иткән чакта без арымый-талмый эшләдек, һәм башкалар икеләнгәндә без куркып тормадык һәм күп укыдык. Әлеге дәрәҗәбез – белем һәм тырышлыгыбыз нәтиҗәсе”. Ә Коръән аларга: “Юк, фетнә (сынау) бит бу! Ләкин аларның күпчелеге белми!” – дип җаваплый (”Төркемнәр” сүрәсе, 39:49).

Язмышның бары тик Аллаһ кодрәтендә булуы һәм бары тик Аллаһның гына кешегә ярдәм итүе аларга мәгълүм булмаудан киләдер бу. Аллаһның бөеклегенә төшенеп җитмәгәнгә күрә тик бер Аллаһка гына гыйбадәт кылырга чакыруны ишеткәндә алар йөзләрен читкә бора. Андыйлар хакында Коръәндә: “Бер Аллаһ кына телгә алынганда Ахирәткә иман китермәгәннәрнең йөрәкләре җирәнү тойгысы кичерә”, – диелә (”Төркемнәр” сүрәсе, 39:45). Шулай итеп, кайчан сез соңгы тапкыр Аллаһның яныгызда булуын тойдыгыз? Кичәме? Әллә үткән атнадамы? Ә бит Аллаһ һәрвакыт безнең хакта хәстәрлек күрә һәм көне-төне безне яклап тора. Ул безгә түгел, ә без Аңа мохтаҗбыз. Без лаек булмасак та, Ул догаларыбызга җавап бирүдән туктамый. Шундый Раббы Аны һәрчак истә тоту һәм Аңа шөкер итеп торуга, Аның белән очрашырга әзерләнүгә, Аның кушканнарын үтәүгә һәм тыйганнарыннан тыелуга лаек түгелмени?!

**Дилбәр БУЛАТОВА әзерләде.**

# ГАҖӘЕП КӨРӘШ

Мәгълүм булганча, Мөхәммәд пәйгамбәр (с.г.в.) Мәккә шәһәрендә туып үскән. Пәйгамбәрлекнең беренче 13 еллык чоры да шул шәһәрдә үтә. Әлеге вакыт аралыгында пәйгамбәребезгә (с.г.в.) бик күп авырлыклар кичерергә туры килә: аңа иярүчеләр булса да, мөшрик булган халыкның күпчелеге аның дәгъватына колак салмый, алай гына да түгел – ачулана, тирги, мыскыллы сүзләр әйтә, кайберләре исә яный, хәтта төрле начарлыклар эшли. Әмма мөшрикләр аңа шундый рәхимсез, явыз мөгамәлә күрсәтүгә карамастан, Мөхәммәд (с.г.в.) барлык кыенлыкларны сабырлык белән кичереп, үзенә хас булган шәфкатьлелеген югалтмый.

Исламга өнди башлауга инде 10 ел тулган көннәрдә пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) белән кызыклы да, гыйбрәтле дә бер хәл була. Дәгъват эшләре буенча ул Мәккә шәһәре чикләрен узып бер авылга юнәлгән чакта, аның каршысына Мәккәнең мәшһүр көрәшчесе, алагаем авыр гәүдәле Рукан исемле баһадир очрый. Бу кеше Мөхәммәд галәйһиссәләмнең мәккәлеләргә сөйләгәннәрен аңламый һәм шуңа күрә аны яратмый иде, шул сәбәпле өндәү-нәсыйхәтләрен дә гел кире кага иде. Шәһәрнең күренекле шәхесен очраткач, Мөхәммәд (с.г.в.) аңа сәлам бирә һәм әйтә:

- Рукан, синең белән бераз сөйләшеп алырга мөмкинме?

Баһадир исә, сәлам кайтарып та тормыйча, кавемдәшенә горур карап, болай ди:

- Сөйләшербез, ләкин башта минем белән көрәшеп кара!

Аңлашыла ки, инде 50 яшен тутырган өлкән кешегә яшь, типсә тимер өзәрлек, моңарчы беркем дә җиңә алмаган көчле көрәшче белән бил алышу мәгънәсез гамәл кебек... Әмма Мөхәммәд пәйгамбәр (с.г.в.) фикере белән Раббысына мөрәҗәгать иткәннән соң, Руканның күзенә туры карап, әйтә:

- Яхшы, көрәшик. Ләкин башта җиңүчегә тиешле бүләк нәрсә булачагын килешик.

Ярышны оттырган кеше җиңүчегә бер сарык бирергә тиешлеген сөйләшкәннән соң, ике көндәш көрәшә башлый. Бер минут та узмый, Мөхәммәд галәйһиссәләм Руканны егып аркасына сала. Нәрсә булганын аңлап та бетермәгән ир җиңелүен танырга мәҗбүр була, әмма моның ялгыш кына килеп чыккан очраклылык булуын әйтеп, тагын бер тапкыр көрәшеп карарга тәкъдим итә.

- Яхшы, ә бу юлы җиңүчегә бүләккә нәрсә була? – дип сораган пәйгамбәргә (с.г.в.) Рукан янә “сарык” дип җавап бирә.

Аллаһы Тәгалә Мөхәммәд салләллаһү галәйһи үә сәлләмнең гайрәтен арттырамы, әллә тәкәббер көрәшчене зәгыйфьләндерәме – безгә мәгълүм түгел, шулай да, пәйгамбәр (с.г.в.) яңадан өстен чыгып җиңә. Аннары тагын берничә мәртәбә көрәшеп карыйлар һәм кабат-кабат җиңелгәннән соң, хәйран калган Рукан әйтә:

- Әй Мөхәммәд, гаҗәпләндердең... Моңарчы мине берәү дә калак сөягенә әйләндереп сала алмады... ә син... Гаҗә-әп...

Мөхәммәд (с.г.в.) исә нурлы күз карашы илә елмаеп, болай ди:

- Әй Рукан, әйдә мин сиңа моннан да гаҗәебрәк булган бер нәрсә күрсәтәм! Күрәсеңме теге агачны?

Рукан күрсәтелгән тарафка борылгач, пәйгамбәр (с.г.в.) күркәм, әмма ышанычлы, нык тавыш белән боера:

- Әй агач! Аллаһ ризалыгы өчен кил минем яныма!

Шул ук мизгелдә куе ботаклы карт агач як-якка авыша-авыша селкенә башлый һәм тамырлары белән бергә җирдән аерылып, Мөхәммәд салләллаһү галәйһи үә сәлләмгә таба юнәлә. Моны карап торучы Рукан күзләрен зур итеп түгәрәкләп, авызын ачып шаккатып телсез кала. Агач исә Аллаһ рәсүле янына килеп җиткәч, бераз иелә дә итагатьле туктап кала. Шуннан соң, Мөхәммәд пәйгамбәр әмер биргәч, агач үз урынына барып, ничек элек торган – шулай урнаша.

Таң калган Рукан ни әйтергә дә белмичә бермәл сүзсез басып тора. Соңыннан тезләнеп пәйгамбәрне (с.г.в..) кулларыннан тотып ала да кычкырып җибәрә:

- Шәһадәт бирәм ки, Аллаһтан башка илаһ юк!!! Һәм шәһадәт бирәм ки, син – Аллаһның илчесе!!!

Әлеге кыйссадан шуны аңлап була: пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһү галәйһи үә сәлләм башкаларга хакыйкатьне җиткергәндә, әңгәмәдәшнең холкын, сәләтен, дәрәҗәсен исәпкә алып аралашырга тырышкан, ул аңлый торган телдә сөйләшкән. Җиңүчегә тиешле сарыкларны да ул, әлбәттә, алмый: әлеге шарт дөнья мәнфәгатьләрен генә кайгыртып яшәүче, мин-минлек сыйфатына ия булган көрәшченең күңеленә керү, аны кызыктыру ысулы буларак кына әйтелә... Ә инде иң мөһиме – башкаларны дингә, иманга өндәгәндә сөекле пәйгамбәребез (с.г.в.) ихлас Аллаһка тәвәккәлләп, йомшак сүзе, хикмәтле гамәле ярдәмендә кешенең акылына гына түгел, йөрәгенә дә тәэсир иткән.

**Ришат КУРАМШИН әзерләде,**
**Кукмара мәдрәсәсе мөдире.**

# Гыйлемең файдалы булсын

Динне саклау өчен гыйлем кирәк. Пычрак савытка әллә нинди, чит илдән килгән кыйммәтле, затлы ризыклар, тәмләткечләр салсаң да, ләззәтле, тәмле ризык әзерләп булмый. Бүген әдәпсез, әзерлексез кешеләрнең хакыйкый остаздан башка Коръән тәфсирләрен, хәдис китапларын укып, алардан ашыгып нәтиҗә ясаулары - агулы казанда аш әзерләү кебек, үзләренә генә түгел, башкаларга да зыян китерә. Иң элек тәүбә-истигъфар кылырга, фарызлардан тыш нәфелләрне дә үтәп, калебне чистартып, тәртипкә китерергә кирәк. Шәкертенең күңеле тәртиптә икәнен белә икән, хакыйкый остаз аңа гыйлем бирергә тиеш. Күп су сипсәң, гөл дә корый, күп ашасаң, ризыкның да файдага караганда зыяны күбрәк. Үзләштерелгән гыйлем үзеңә, гаиләңә, җәмгыятькә



файда китерерлек булырга тиеш.

***Җәлил хәзрәт ФАЗЛЫЕВ,***
**Татарстанның баш казые.**

## Колак салсаң, үкенмәссең

** Аллаһы Тәгаләнең хәрам иткән нәрсәләреннән саклан - гыйбадәт кылучы булырсың.*

** Күршеңә гүзәл мөгамәлә ит - мөэмин булырсың.*

** Аллаһы Тәгалә биргән нәрсәләргә риза бул - бай адәмнән саналырсың.*

** Үзең өчен сөйгән нәрсәләрне башкалар өчен дә сөй - мөселман булырсың.*

** Күп көләргә гадәтләнмә - күп көлү күңелне үтерә.*

** Бәндә теләнчелек ишеген ачса, Аллаһ ул кешегә фәкыйрьлек ишеген ачар.*

## “Реалист”

Үзен фәһем иясе исәпләгән бер бәндә болай дип лаф ора икән:

- Мин реалист, чынбарлык кешесемен. Күзем белән күрмәгән нәрсәгә ышанмыйм, - дип торганда, янындагы кеше аның җилкәсенә берне кундырып ала.

Теге бәндә кычкыра башлый:

- Нишлисең син, әй? Авыртуы башыма капты, - ди.

Суккан кеше әйтә:

- Юк, бер җирең дә авыртмады. Минем йодрык беркайчан да авырттырмый. Әгәр авырттырды дисең икән, әйт әле, ничек авырттырды? Авыртуның иңен-буен күрсәт!

“Реалист бәндә”, табигый, авыртуның дәрәҗәсен берничек тә күрсәтә алмый, җавап бирүдән гаҗиз кала.

**Мәтин ӘРИШ.**

## Бергә булыйк!

Хөрмәтле укучыларыбыз!

“Ислам нуры” газетасы 1995 елдан бирле чыгып килә. Алла боерса, алда - 25 еллык юбилее! Шушы вакыт аралыгында күпләрегез яратырга өлгергән бай эчтәлекле газета ул. Кулдан язылган хатларыгызны алып уку, андагы теләк-тәкъдимнәрегезне, җылы сүзләрегезне ишетү безнең өчен дә бик күңелле. Ике арадагы шушы элемтәләр өзелмәсен, алдагы көннәрдә дә бергә булыйк! Газета битләрендә белдерүләр, реклама текстлары да урнаштырырга мөмкин. “Ислам нуры”на почта бүлекләрендә, Татарстан буенча гына түгел, Россиянең бөтен төбәкләрендә язылырга мөмкин. “Роспечать” каталогында, индексы – 54149.



*Балалар өчен*

### Кәләпүшем, кәләпүш



Йөзләремә килешәсен
Кайлардан гына белгән,
Туган көнгә дәү әтием
Кәләпүш алып килгән.
Кәләпүшем, кәләпүш,
Энҗе-мәрҗәннәр чиккән.
Чиккән кәләпүш үземә
Бигрәк килешә икән!
Кәләпүшемне кидем,
Көзге каршына килдем.
“Менә шушындый була ул
Татар малае!” - дидем.
Кәләпүшем, кәләпүш,
Энҗе-мәрҗән читләре.
Шундый матур кәләпүшле
Егет булдым бит әле!

**Резеда Вәлиева.**

**Саулыгым – байлыгым**

## Хөрмә



Хөрмә организмнан токсиннар һәм шлакларны чыгара, симерүгә каршы нәтиҗәле чара булып тора. Ул иммунитетны күтәрә, хәтерне яхшырта. Өлгергән хөрмә кызгылт-сары тутларга бай, ә ул тутлар күз күремен яхшырта, сулыш юллары, үпкә ялкынсынуы барлыкка килүгә каршы тора. Хөрмә йөрәк мускулы өчен дә файдалы, кан тамырлары тышчаларын да ныгыта. Кан басымын җайга сала һәм гипертониядән булыша. Хөрмә эчәклек эшчәнлеге бозылганда да файдалы, ашказаны авыртканда авыртуны басарга ярдәм итә. Өлгергән хөрмә җимешләре бик яхшы бөрештерү һәм микробларны үтерү сәләтенә ия. Шуңа күрә дә җимешне ярага яки пешкән урынга куеп торсаң, яра тиз төзәләчәк. Хөрмә белән ясалган чәй азканлылык вакытында файдалы. Хөрмә ашау нерв киеренкелегеннән котылырга, йокыны яхшыртырга ярдәм итә. Тамакны берничә көн буе хөрмә суы һәм бер стакан җылы су кушылмасы белән чайкасагыз, тамак авырту тиз үтәр. Шуны да онытмагыз: хөрмә ашаганнан соң, тешләрне чистартырга кирәк. Чөнки андагы кайбер матдәләр кариесны көчәйтә.

**Нәшире**
**Иршат Гыйльметдин улы ШӘЙХАТТАР**

**Баш мөхәррир**
**Муллагалиева А. Г.**

**Тел.:** (8552) 70-51-09
**Факс:** (8552) 70-51-45

* * *

**Оештыручылары:**
Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәте, “Ислам нуры” дини эшмәкәрлек Үзәге

Газета мәкаләләрен күчереп басканда аларның “Ислам нуры”ннан алынганын күрсәтү мәҗбүри.

Редакциягә килгән хатларда авторларның стиле саклана.

**Хатларны 423802, Чаллы Үзәк ур., 72 адресы буенча юллау кирәк.**

**Электрон хатлар өчен:**
islamgazeta@mail.ru

Мөселманнар арасын бозуга, үзара каршылыкларга китерергә мөмкин булган хатлар, шикаятьләр газетада басылмый.

Дин-шәригать мәсьәләләренә кагылышлы язмалар, укучы сораулары Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые, Чаллы төбәге мөхтәсибәтенең гыйльми Советы тарафыннан өйрәнелә һәм аларга җавап бирелә.

Россия Федерациясе матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникацияләр Министрлыгының Идел буе төбәкара территориаль идарәсендә ПИ № 7-0997 саны белән 2001 елның 15 ноябрендә теркәлде.

“Роспечать” агентлыгы каталогына кертелгән, язылу ел әйләнәсендә Россия Федерациясе буенча алып барыла.

Айга ике мәртәбә чыга.

**Тиражы: 1500**
**Индексы 54149**

* * *

Хөрмәтле укучыбыз!

Газетабызны укып чыккач, аны туганнарыгызга, танышларыгызга, тапшырсагыз иде. “Ислам нуры”ның һәр саны кулдан-кулга күчеп динебезне таратырга ярдәм итсә иде. Әмин.

Шулай ук укучыларыбыз, Коръән аятьләре язылу сәбәпле, газетаны кирәкмәгән урыннарга ташлаудан сакланырлар дип ышанабыз.

* * *

Газета компьютерда җыелды, офсет ысулы белән “Ислам нуры” басмаханәсендә басылды.

**Нәшир, типография һәм редакция адресы:**

**423802, Яр Чаллы, Үзәк урамы, 72**

**Басарга кул куелды:**
**график буенча**
**24 декабрь 16 сәг.**
**фактта 24 декабрь 16 сәг.**

**Бәясе ирекле**